**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе турында» 2012 елның 16 маендагы ПУ-342 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 4 мартындагы ПУ-233 номерлы, 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-888 номерлы, 2018 елның 16 мартындагы ПУ-236 номерлы һәм 2019 елның 6 августындагы ПУ-451 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәдә:

6 пунктта «рәис урынбасары» сүзләрен «рәис урынбасарлары» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Комиссия рәисе булмаган вакытта, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе карары нигезендә аның урынбасарларыннан берсе башкара.»;

б) Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе составын кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 08 июль
№ ПУ-387

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «08» июлендәге
ПУ-387 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Кузюров<br>Равил Әфраим улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры, Комиссия рәисе |
| Соколов<br>Алексей Владимирович | Татарстан Республикасы Эчке эшләр министры урынбасары – полиция башлыгы, Комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Илгизәр Наил улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары |
| Әхмәров<br>Айрат Фәргать улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы, Комиссия секретаре |
| Гайнетдинова<br>Лилия Әхәт кызы | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Галиев<br>Илнур Наил улы | Федераль ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Кашафов<br>Рамил Васил улы | Дәүләт милкенә идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасында һәм Ульяновск өлкәсендә төбәкара территориаль идарәсенең кулга алынган, конфискацияләнгән һәм башка милекне бәяләү, сату бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Нәбиуллина<br>Лилия Мөхәммәт кызы | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы (килешү буенча) |
| Ситдыйков<br>Марат Мәхмүт улы | Дәүләт милкенә идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасында һәм Ульяновск өлкәсендә төбәкара территориаль идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Хисаметдинова<br>Гүзәл Тәлгать кызы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының урман эшкәртү һәм җиңел сәнәгать бүлеге башлыгы |
| Хренов<br>Валерий Витальевич | Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Йосыпов<br>Марсель Мәгъсүм улы | Урман хуҗалыгы федераль агентлыгының Идел буе федераль округы буенча Урман хуҗалыгы департаменты федераль дәүләт урман күзәтчелеге һәм үзагачны исәпкә алуга контроль бүлеге дәүләт инспекторы (килешү буенча) |

___